УДК 811(=512.1)

*Х.Ч. Алишина*

# ЭЛГӘРЛӘРЕБЕЗНЕҢ ФӘННИ МИРАСЫ: тюрколог, борынгы уйгур теле белгече профессор Д.М. Насиловның тууына 90 ел тулу уңаеннан

Статья посвящена научно-педагогической деятельности крупнейшего ученого-востоковеда, единственного в России специалиста по древнеуйгурскому языку, автора более 250 научных и научно-методических трудов, словарей и монографий Дмитрия Михайловича Насилова (1935–2017). Рассматриваются ключевые этапы его биографии как ученого и педагога, руководителя и общественного деятеля, определяются магистральные линии научных изысканий, дается краткий обзор наиболее значимых трудов. Автор статьи раскрывает роль Д.М. Насилова в возрождении национальных культур в 1990-е гг., сохранении научных традиций, популяризации достижений российской науки на международном уровне. Особая роль в публикации отведена освещению доклада, прозвучавшего на Международной тюркологической конференции 85-летию памяти академика Д.Г. Тумашевой, с которой его связывала многолетняя творческая дружба.

**Ключевые слова:** Дмитрий Михайлович Насилов, тюркология, ученый-востовокед, древнеуйгурский язык, грамматика тюркских языков.

The article is devoted to the scientific and pedagogical activities of the leading orientalist, the only specialist in the ancient Uyghur language in Russia, the author of more than 250 scientific and scientific-methodical works, dictionaries and monographs Dmitry Mikhailovich Nasilov (1935–2017). The key stages of his biography as a scientist and teacher, leader and public figure are considered, the main lines of scientific research are determined, a brief overview of the most significant works is given. The author of the article reveals the role of D.M. Nasilov in the revival of national cultures in the 1990s, the preservation of scientific traditions and the popularization of the achievements of Russian science at the international level. A special role in the publication is given to the coverage of the report delivered at the International Turkological Conference on the 85th anniversary of the memory of Academician D.G. Tumasheva, with whom he had a long-standing creative friendship.

Keywords: Dmitry Mikhailovich Nasilov, Turkic studies, Orientalist scholar, ancient Uyghur language, grammar of Turkic languages.

Дмитрий Насилов 1935 елның 18 мартында Мәскәү өлкәсе Зарайск шәһәрендә зыялылар гаиләсендә дөньяга килә. Һөнәр сайлауда якын туганы, шәркыятчы галим, педагог, профессор, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе Владимир Михайлович Насиловның йогынтысы зур була.

Дмитрий Михайлович Насилов бөтен гомерен төрки телләрне өйрәнүгә багышлый. Керү имтиханнарын уңышлы тапшырып, ул МДУның филология факультеты Көнчыгыш бүлегенә хәзерге (төрек, үзбәк) һәм борынгы төрки телләр белгечлегенә укырга керә.

Биредә Себер татарлары телен фәнни өйрәнүгә нигез салучы, Казан дәүләт университеты профессоры, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты, нигез салынган көннән Совет (хәзер Россия) тюркологлары комитеты әгъзасы, Türk Dil Kurumu Төркия лингвистика җәмгыятенең мактаулы әгъзасы Диләрә Гариф кызы Тумашева, филология фәннәре докторы, РФА Тел белеме институты Урал-Алтай телләре бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Галина Федоровна Благова һ.б. укый.

А.В. Шеймович «К 85-летию Галины Федоровны Благовой: научные итоги десятилетия» дигән мәкаләсендә болай дип билгеләп үтә: «Г.Ф. Благованың университеттагы укытучылары – Самойлович фәнни мәктәбен дәвам иткән Н.К. Дмитриев, Самойловичның үзендә укыган Ә.Н. Нәҗип һәм В.М. Насилов» [6: 4]. Танылган шәркыятчылар Николай Константинович Дмитриев, Әмир Нәҗип улы Нәҗип, Владимир Михайлович Насилов, Эрванд Владимирович Севортянда Дмитрий Михайлович Насилов та укый. Бу – тюркологиягә ихлас күңелдән бирелгән галимнәрнең искиткеч плеядасы.

Галина Федоровна Благова белән Диләрә Гариф кызы Тумашева яшьтәшләр була. Студент еллары 1944–1949 елларга туры килгән Д.Г. Тумашева үзенә аеруча кадерле булган педагогларны – фәнни җитәкчесе, Мәскәү тюркологлар мәктәбенә нигез салучы, СССР ФА мөхбир әгъзасы, профессор Николай Константинович Дмитриевны, гарәбиятчы Бенциан Меерович Грандены, иранист Борис Всеволодович Миллерны, тюрколог Эрванд Владимирович Севортянны, фольклорчы Мәдинә Искәндәр кызы Богданованы зур хөрмәт белән искә ала [1: 7].

Д.М. Насиловның яшьлеге, студент еллары Көнчыгышта милли азатлык хәрәкәте күтәрелгән чорга туры килә. Илгә төрки телләр буенча Мәскәү шәркыяте позициясен үстерергә һәм ныгытырга сәләтле югары квалификацияле белгечләр кирәк була. Дмитрий Михайлович, төрки филология кафедрасында диплом эшен «бик яхшы» билгесенә яклап, МДУны 1958 елда тәмамлый. ДИК (ГЭК) карары белән аңа шәркыятчы филолог, филология фәннәре өлкәсендә фәнни хезмәткәр, югары уку йорты укытучысы квалификациясе бирелә.

Мәгариф министрлыгы юлламасы белән Д.М. Насилов Үзбәкстанга китә һәм 1958–1960 елларда Сәмәрканд университетының үзбәк теле кафедрасында укытучы булып эшли. 1964 елда Мәскәүдә Тел белеме институты каршындагы аспирантураның көндезге бүлеген уңышлы тәмамлап, «Структура времени индикатива в древнеуйгурском языке (по памятникам уйгурского письма)» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. Бүгенге көнгә кадәр Д.М. Насилов Россиядә борынгы уйгур теле һәм аның язуы буенча бердәнбер белгеч санала.

Д.М. Насиловның максатчан фәнни эшчәнлеге 1963 елдан башлап утыз ел дәвамында Тел белеме институтының (хәзер Россия

фәннәр академиясе Лингвистик тикшеренүләр институты) Ленинград бүлеге белән бәйле була. Анда ул алтай телләре секторы җитәкчелеге тарафыннан эшкә чакырыла. Бередә Дмитрий Михайлович үзенең эшчәнлеген кече фәнни хезмәткәр буларак башлый һәм РФА Лингвистик тикшеренүләр институты алтай телләре бүлеге мөдире дәрәҗәсенә күтәрелә. Д.М. Насилов, мәкаләләр авторы һәм мөхәррирләрнең берсе буларак, бик сирәк очрый торган китапны – «Древнетюркский словарь»ны басмага әзерләү белән шөгыльләнә. Үз вакытында В.В. Радлов, С.Е. Малов эшли башлаган сүзлеккә төркиләрнең бөтен алфавитларындагы (Орхон, төрки, гарәп, манихей) лексика теркәлгән – барлыгы 6000 сүз һәм гыйбарә. Бу елларда Дмитрий Михайлович төрки филология өлкәсендә илебезнең иң танылган һәм атказанган галимнәренең берсе була, төрки телләрнең теоретик грамматикасына зур өлеш кертә, алтай телләрендә фигыльнең грамматик категорияләрен җентекләп өйрәнә.

Д.М. Насиловның фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешен фигыль категорияләре темасы тәшкил итә. Искәртеп үтәм: фигыль – минем фәнни җитәкчем, ТР Фәннәр академиясе академигы Диләрә Гариф кызы Тумашеваның да иң яраткан сүз төркеме иде. Яшь аермасы шактый булуга карамастан, Россиянең ике атаклы тюркологын – Диләрә Гариф кызын һәм Дмитрий Михайловичны күпьеллык иҗади дуслык бәйләп тора. Минемчә, аларны МДУның алар икесе дә укыган факультетына тугрылык, уртак фәнни мәнфәгатьләр, танылган укытучыларына хөрмәт якынайта.

Дмитрий Михайловичны *вид* мәсьәләсе борчый, чөнки төрки телләрдә, рус һәм башка славян телләрендәге кебек, аның аналогы юк, әмма «есть признаки, которые связываются с понятием аспекта в общей лингвистике» [3: 4]. Бу тема беренче мәртәбә Д.М. Насиловның «О способах выражения видовых значений в алтайских языках» дигән хезмәтендә күтәрелә. Галим 30 га якын хезмәтен әлеге проблеманың төрле аспектларына багышлый, бу «Наука» нәшриятында Ә.Р. Тенишев редакциясендә нәшер ителгән «Проблемы тюркской аспектологии. Акциональность» монографиясендә чагылыш таба. Кулъязма Дмитрий Михайлович эшләгән кафедра әгъзаларында, хезмәттәшләрендә зур кызыксыну уята. Шунысы игътибарга лаек: кулъязманы тикшерүдә себер (бараба) татарлары теле белгече, филология фәннәре докторы Людмила Васильевна Дмитриева да актив катнаша. Китапның рецензентлары – филология фәннәре докторы В.М. Павлов, филология фәннәре кандидаты Е.А. Кузьменков.

Галимнәр төрки вид проблемасына багышланган бу монографиянең аеруча әһәмиятле һәм кирәкле булуын таныйлар. Монография Дмитрий Михайловичның докторлык диссертациясенең дә нигезен тәшкил итә. Мәгариф һәм фән министрлыгының Югары аттестация комиссиясе Д.М. Насиловның фәнни казанышларын югары бәяли. 1990 елның 3 августында «Проблемы тюркской аспектологии: акциональность» дигән темага диссертация яклаганнан соң, ул филология

фәннәре докторы дипломын ала. Алга таба бу юнәлештәге тикшеренүләр типологик характерда бара. «Акциональность в алтайских языках. Типология и “детерминанта”» хезмәтендә алтай телләре чагыштырып өйрәнелә.

XX гасыр ахыры Казан тюркологлары өчен дә уңышлы була. КДУ профессоры Д.Г. Тумашева татар теле морфологиясен, аерым алганда татар фигыльләрен, өйрәнү буенча фәнни эш белән актив шөгыльләнә. 1986 елда аның миңа язган хатыннан бер өземтә китерәм: «…к 15 декабря я должна дать еще одну статью, чисто грамматическую: взаимодействие грамматических категорий глагола. Затем у меня доклад на пленарном заседании итоговой научной конференции “Способы номинации пространственной характеристики действия”, потом, на конференцию, посвященную Г. Ибрагимову – “Стилистика глагольных форм” и т. д.» [4: 237].

Профессор Д.Г. Тумашева татар телен, Себер татарлары диалектларын өйрәнү буенча зур фәнни-тикшеренү эше алып барган өчен 1991 елда Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең беренче хатын-кыз академигы итеп сайлана. Татарстан Республикасының әйдәп баручы тюркологлары М.З. Зәкиев, Ф.Ә. Ганиев, Д.Г. Тумашева, К.З. Зиннәтуллина тарафыннан эшләнгән өч томлы «Татар грамматикасы» тел белемендә зур казаныш һәм беренче җитди фәнни басма буларак бәяләнә.

Д.Г. Тумашеваның татар фигыле темасын аеруча яратып өйрәнүе турында алда әйтелгән иде. Әйтелгәннәрне раслап, 2001 елда язылган хатыннан тагын бер кечкенә өземтә китерәм: «Напишу и о себе. Очень устаю. К концу года сдали коллективную монографию на татарском языке. Я – руководитель и мною лично написаны два раздела: “Лексическое и лексико-грамматическое значение глагола” и “Функционально-семантические категории модальности, темпоральности, персональности” – 150 страниц компьютерного текста» [5: 253].

Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Төрки телләр диалектологиясе, тарихы һәм грамматик структурасы» Халыкара тюркологик конференциясе академик Д.Г. Тумашеваның тууына 85 ел тулуга багышлап уздырыла. Дмитрий Михайлович Насилов «Программный труд академика Д.Г. Тумашевой» дигән доклад белән чыгыш ясый, анда, аерым алганда, мондый сүзләр бар: «С творческой деятельностью виднейшего татарского филолога Д.Г. Тумашевой непосредственно связан тот научный сдвиг, который определил и, с нашей точки зрения, определяет теоретические направления в татарском языкознании» [2: 10].

Дмитрий Михайлович «Татарский глагол: Опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий» китабын Д.Г. Тумашеваның программ хезмәте дип атый: «Данное учебное пособие отражает определенный этап исследования структуры

татарского глагола, осуществляемого на кафедре татарского языка Казанского университета. В нем получил отражение функционально-семантический аспект анализа глагольных форм и категорий. В пособии использован опыт предшествующих исследований по морфологии татарского глагола, в том числе диссертационных работ по глаголу Ф.М. Хисамовой, М.Б. Мардиевой, Н.Х. Салеховой, Д.Ш. Шайхайдаровой, Р.С. Абдуллиной, выполненных под руководством автора» [5: 10].

Д.М. Насилов фикеренчә, Д.Г. Тумашева татар теленең фигыль (һәм фигыльләрнең генә дә түгел!) категорияләрен функциональ-семантик аспектта һәм кыр структуралары кысаларында өйрәнүнең комплексы программасын тәкъдим итә. «Значительных успехов добились грамматисты в изучении глагольных категорий, особенно продуктивным оказалось описание поля аспектуальности в тюркских языках. Большой прорыв в этом отношении был связан с работами Ф.А. Ганиева, впервые широко использовавшего понятие способа глагольного действия применительно к татарскому глаголу» [2: 10].

Д.М. Насилов Казан галимнәре – академик Д.Г. Тумашева, ТР ФА мөхбир әгъзасы Ф.А. Ганиев – төрки тел белемендә концептуаль яктан өч юнәлешкә нигезләнгән фәнни мәктәпкә нигез салды, дип саный һәм пленар утырышта ясаган докладында әлеге юнәлешләрне җентекләп бәян итә.

«Во-первых, на материале тюркских языков была поставлена и получила конкретное обоснование идея о различении собственно видовых значений (аспект) и значений способов глагольного действия (акционсарт) как соотносительных, но содержательно разных языковых явлений, представленных в этих языках различающимися грамматическими средствами. В русле этого направления был выполнен целый ряд работ, в которых получили описание способы действия отдельных языков.

Во-вторых, наметилась определенная тенденция рассматривать систему временных форм как систему видовременных форм, в которых оказываются сопряженными аспектуальные и темпоральные значения.

Это побуждает исследователей не только углубляться в анализ состава значений отдельных временных форм, но и стремиться к определению их системных значимостей, особенно при наличии многочленных парадигм. Здесь же встают вопросы о соотношении в формах глагола временной и аспектной семантики, играющие важную роль при диахронических исследованиях, когда изучается генезис темпорально-аспектных категорий в том или ином тюркском языке. Наблюдения, накопленные в этом направлении, небезынтересны и для типологии языкового развития.

В-третьих, в современной тюркологии все возрастающее внимание уделяется функциональному подходу к описанию категорий, при котором существенное место отводится взаимодействию лексического

и морфологического уровней языка. Поэтому не случайно выясняются связи между лексическим значением глагола, его предельным/непредельным характером, принадлежностью к определенной семантической группе и образуемыми от него грамматическими формами. Уточняются и синтагматические связи глагольных словоформ, зависимость семантики последних от контекста. При этом особое внимание обращается на особенности функционирования и реализации конкретного значения глагола в каждом отдельном высказывании, то есть выделяются прежде всего значимые элементы контекста, выясняется роль аспектуального контекста, способствующего проявлению аспектуальной характеристики действия» [2: 11].

Халыкара юбилей конференциясенең пленар утырышында, үзенең докладын йомгаклап, Дмитрий Михайлович болай дип ассызыклый: «25 лет тому назад Д.Г. Тумашева своей работой показала, что на основе новейших грамматических разработок и при соответствующей реинтерпретации накопленного языкового материала возможен новый взгляд на некоторые глагольные категории татарского языка, то есть продвинувшееся новое теоретическое знание влечет за собой переоценку эмпирических фактов» [2: 12].

Танылган галимнең хезмәт биографиясендәге бер мөһим моментны билгеләп үтәргә кирәк: Санкт-Петербургта яшәсә дә, Д.М. Насилов беркайчан да Мәскәүдәге коллегалары белән элемтәне өзми, «Төрки телләрнең этимологик сүзлеге» коллективында эшли, сүзлеккә мәкаләләр язуда да, РФАнең Тел белеме институты тюркологлары тарафыннан башкарылган «Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков» дип исемләнгән күп томлы планлы хезмәтне эшләүдә дә катнаша.

Галим Д.М. Насилов ярты гасырдан артык укыту эшчәнлегеннән аерылмады. Зур һәм абруйлы тюрколог, төрки тел белеме буенча күренекле белгеч буларак, ул Петербург дәүләт университеты Көнчыгыш факультетының төрки филология кафедрасында гына түгел, ә илнең башка әйдәп баручы югары уку йортларында да лекция курслары укый. Миңа 1989 елның октябрендә Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм Көнчыгыш телләре факультеты аспирантурасында профессор Д.М. Насиловның «Борынгы төрки язма һәйкәлләр теле» дигән лекцияләр курсын тыңлау һәм аның үзенә зачёт тапшыру насыйп булды. Профессорның мин тырышып-тырышып конспектлаган һәр сүзе актуаль, еллар үтү белән аларның кыйммәте арта гына бара, алардан зур фәнни энергия бөркелә. КДУ аспирантлары алдында чыгыш ясаганда, лектор Д.М. Насилов һунну, сяньби, төрки каханлыклар, борынгы уйгур, манихей, Орхон-Енисей алфавитлары тарихын тәфсилләп аңлатты, Дмитрий Дмитриевич Васильев («Корпус древнетюркских памятников Енисея»), Сергей Ефимович Малов хезмәтләрен («Памятники древнетюркской письменности», «Енисейская письменность тюрков») җентекләп анализлады, бу китапларны табып өйрәнергә киңәш итте. Д.М. Насиловтан

алган бәһасез белемнәр, галимнең тышкы кыяфәте, югары культуралылыгы, абруе, зыялылыгы бездә – Көнбатыш Себер, Казахстан, Үзбәкстан, Таулы Шория, Якутия, Хакасия, Таганрогтан килгән аспирантларда тирән ихтирам хисе уятты. Алган белемнәребез безгә – яшь тюркологларга – алдагы тормышыбызда бик ярап куйды. Алда бит әле һәрберебез әлеге компетентлы профессор белән берничә тапкыр очрашты. Ул безнең югары уку йортларына, көтелгән хөрмәтле кунак буларак, симпозиумнарга, конференцияләргә, форумнарга, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренең оппоненты сыйфатында махсуслаштырылган фәнни советларга килә.

1993 елда профессор Дмитрий Михайлович Насиловны РФ Милләтләр эшләре буенча һәм төбәк сәясәте министрлыгы каршында оештырылган Россия Федерациясе халыклары телләре институтына чакыралар, анда ул институт директоры урынбасары вазифасын башкара. Бу – ил тормышында яңа чор, милли мәдәниятләрне торгызу этабы була. Төмән дәүләт университетында, В.И. Ленин исемендәге Мәскәү педагогия институтында, Оренбург, Тубыл һәм башка педагогия институтларында татар бүлекләре нәкъ менә шул елларда булдырыла. РФ милләтләр эшләре буенча һәм төбәк сәясәте министрлыгы бу чорда Халыкара төрки академия оештыру буенча зур эш алып бара, аның президенты итеп абруйлы тюрколог, РФА мөхбир әгъзасы Әдһәм Рәхим улы Тенишев билгеләнә, хакыйкый әгъзалары итеп Дмитрий Михайлович Насилов, Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев, Игорь Валентинович Кормушин, Рашид Абдулла улы Саликов, Шамил Фатих улы Мөхәммәдьяров, Фоат Тач-Әхмәт улы Вәлиев, Ирек Г. Акманов, Николай Константинович Антонов, Марат Вәли улы Зәйнуллин, Зиннур Газиз улы Ураксин, Кази Танай улы Лайпанов, Хәнисә Чайдат кызы Алишина һ. б. сайлана.

1996 елда Дмитрий Михайлович М.В. Ломоносов исемендәге МДУның Азия һәм Африка илләре институты төрки филология кафедрасы профессоры итеп сайлана. Д.М. Насилов югары квалификацияле фәнни-педагогик кадрлар әзерләүдә, фәнни традицияләрне саклауда зур тәҗрибәгә ия. Ул студентлар һәм аспирантлар өчен лекция курслары әзерли һәм укый: «Алтаистика тарихы», «Борынгы төрки язма истәлекләр теле», «Борынгы уйгур теле», «Үзбәк теле», «Төрки телләрнең чагыштырма грамматикасы нигезләре», «Төрки лексикология», «Төрки телләрнең функциональ грамматикасы нигезләре», «Тюркологиягә кереш», «Рус һәм үзбәк телләренең чагыштырма грамматикасы» һ.б.

Профессор Дмитрий Михайлович Насиловның фәнни хезмәтләре белән бөтен дөнья тюркологлары таныша, дияргә мөмкин. Алар галимнең түбәндәге монографияләрен югары бәялиләр: «Проблемы тюркской аспектологии: Акциональность», «Концепция языкового типа в трудах Н.А. Баскакова», «Значение» и «функция» в функциональной грамматике А.В. Бондарко», «Языки малочисленных этносов в образовательном пространстве России» һ. б. Профессор

Д.М. Насилов РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, мәктәп укытучыларына зур фәнни-методик ярдәм күрсәтә. «Россия Федерациясе Төньягының азсанлы җирле халыклары өчен этник (милли) мәктәп моделе концепциясе», «Төньяк халыклары мәктәпләре өчен тунгус-маньчжур төркеме телләре буенча типовой гомуми белем бирү программасы», «Милли мәктәп өчен туган һәм рус теле дәреслеге концепциясе» иҗади хезмәттәшлекнең нәтиҗәсе булып тора.

Элгәрләренең фәнни мирасын өйрәнүгә Д. М. Насилов зур әһәмият бирә: ул – В.В. Радлов, С.Е. Малов, О.Н. Бетлинг, П. М. Мелиоранский һ.б. турында мәкаләләр, хезмәтләр авторы. Алар арасында Д.М. Насиловның Ф. Д. Ашнин һәм В.М. Алпатов белән бергә язылган «Репрессированная тюркология»се (2002) һәм А.Н. Самойловичка һәйкәл-китабы (2005) аерылып тора. Соңгысында XX гасырның әйдәп баручы тюркологларыннан берсе булган галимнең (1938 елда репрессияләнә) төп хезмәтләре искә төшерелә һәм шәрехләнә [3: 12].

Галим Д.М. Насиловның фәнни һәм иҗади эшчәнлеге күпкырлы. Ул 100 дән артык халыкара, бөтенроссия һәм төбәк конференцияләрендә һәм симпозиумнарда актив катнаша. Алар арасында иң әһәмиятлеләре: мәсәлән, 38 Халыкара шәркыятчылар конгрессы (ИКАНАС-38) – Төркия, Әнкара (2007); күренекле галим Мәхмүд Кашгарига һәм аның «Диване лөгатет-төрк» сүзлегенә багышланган халыкара симпозиум (Левкоша) (2008); III Халыкара тюркология корылтае (Левкоша) (2008). Күренекле фәнни хезмәтләре өчен профессор Дмитрий Михайлович Насилов академик – Türk Dil Kurumu төрек лингвистика җәмгыятенең чит ил әгъзасы итеп сайлана.

Россия (элек Совет) тюркологлары комитеты әгъзасы һәм аның җитәкчеләренең берсе буларак та Д.М. Насилов зур оештыру, берләштерү эшен башкара. Әлеге комитетның, аның элекке рәисләре Андрей Николаевич Кононов, Әдһәм Рәхим улы Тенишевның, хәзерге җитәкчеләре Игорь Валентинович Кормушин, Дмитрий Михайлович Насиловның эшчәнлеге нәтиҗәсендә илебезнең барлык тюркологлары тыгыз фәнни бәйләнештә яши. Шулай итеп, Дмитрий Михайлович Насилов бөтен фәнни эшчәнлеге дәвамында зур, күпмилләтле тюркологик коллективта хезмәт куя. Һәм ул Россия Фәннәр академиясенең Тарих-филология фәннәре бүлеге каршындагы Россия тюркологлары комитеты әгъзасы, ә аннары аның рәис урынбасары булган вакытта махсуслаштырылган фәнни мәсьәләләрне кую һәм хәл итү зарурлыгы туа. 2009 елда Россия Фәннәр академиясе, Россия фәннәр академиясенең Тел белеме институты, Россия тюркологлары комитеты химаясендә «Российская тюркология» журналы яңадан чыга башлый, аның баш мөхәррире итеп Д.М. Насилов сайлана.

Галим Дмитрий Михайлович Насиловның җәмәгать эше Россия фәннәр академиясенең Тарих-филология фәннәре бүлеге каршындагы Россия тюркологлар комитеты рәисе урынбасары, Россия тюркологлар комитеты органы булган «Российская тюркология» журналының

баш мөхәррире вазифалары белән генә чикләнми. Берничә ел дәвамында профессор Дмитрий Михайлович Насилов РФ Дәүләт Думасының Милләтара мөнәсәбәтләр комитетында эксперт булып тора. Аны еш кына Россия халыкларының мәдәнияте һәм телләре буенча төрле иҗади конкурсларда жюри рәисе булырга чакыралар.

XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында халыкара фәнни бәйләнешләрне киңәйтү һәм урнаштыруда алга китеш күзәтелә. Россия ПИАКның ел саен җыела торган халыкара алтаистика конференцияләрендә катнаша башлады. Чит илләрдә безнең фәнне күп еллар дәвамында Дмитрий Михайлович Насилов тәкъдим итә. Мондый конференцияләрдә Көнбатыш галимнәре безнең илдәге зур казанышлар белән таныша алалар.

2014 елның җәендә төрки әдәби телләр тарихы буенча хезмәтләре белән танылган профессор Дмитрий Михайлович Насилов «Тюркология» өлкәсенә зур өлеш керткән өчен Төркия Республикасының «Лиякат» ордены белән бүләкләнә. Бу орден чит ил кешеләренә Тышкы эшләр министрлыгы һәм Төркия Республикасының мәдәният, тел һәм тарих буенча Ататөрк исемендәге Югары советы тәкъдиме буенча Төркия Республикасы Президенты тарафыннан тапшырыла.

«Лиякат» ордены белән бүләкләнүчеләр арасында Ә.Р. Тенишев (Россия), Джеффри Льюис (Бөекбритания), Жан-Поль Ру (Франция), Геза Давид (Венгрия), Омельян Прицак (АКШ), Бубуйна Орузбаева (Кыргызстан), Камил Вели Нериманоглу (Азәрбайҗан), Андреас Рона-Таш (Венгрия), Виктор Гузев (Россия), Роберт Данков һәм Вальтер Дж. Эндрюс (АКШ), Ларс Йохансон (Швеция), Георг Хазаи (Венгрия), Абдурехити Якуфу (Кытай), Эвангелиа Балта (Греция), Клаудиа Ремер (Австрия) һ. б. бар.

Дмитрий Михайлович Насиловны бүләкләү тантанасында 500 дән артык кеше була – Төркия парламенты спикеры, Төркия вице-премьеры, министрлар, депутатлар, илчеләр, язучылар, фән һәм сәнгать учреждениеләре башлыклары, дөнья университетларының тюркология бүлекләре җитәкчеләре, укытучылар катнаша. Төркия Президенты Абдуллаһ Гүл үзенең чыгышында болай ди: «Кадерле дустыбыз Дмитрий Михайлович Насилов 56 еллык һөнәри тормышында үзенең хезмәтләре һәм язмалары белән тюркологиягә зур өлеш кертте, һәм менә дигән шәкертләр тәрбияләп, безне сөендерде. Мин Сезне котлыйм һәм фәнни эшчәнлегегездә алга таба да уңышлар телим» [12: 108].

Хаҗеттепе университетының төрек теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, «Российская тюркология» журналының редакцион советы әгъзасы, профессор, фән докторы Шөкрү Халюк Акалын, котлап чыгыш ясаганда, талантлы галимнең фәнни хезмәтләренең әһәмиятен һәм аңа хас кешелеклелек сыйфатларын аерым ассызыклый: «Дмитрий Михайлович Насилов, Төрки телләр үсешен тарихи чорларга бүлү мәсьәләләре буенча үзенчәлекле, компетентлы һәм кыйммәтле фәнни хезмәтләре аркасында төрки дөньяда әһәмиятле урында тора,

шуның белән бергә ул кешеләргә үтә гади, ихтирамлы, кисәтүчән мөнәсәбәте белән бөтен фәнни дөньяның хөрмәтен яулады» [7: 108].

Дмитрий Михайлович Насилов – төрки телләр теориясе һәм тарихы өлкәсендә зур белгеч, 250 дән артык фәнни һәм фәнни-методик хезмәтләр, сүзлекләр һәм монографияләр авторы, күп еллар М.В. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының Азия Һәм Африка илләре институтында төрки филология кафедрасын җитәкли. Аның җитәкчелегендә бик яхшы галимнәр һәм укытучылар плеядасы әзерләнгән. Докторантларга, аспирантларга, диплом һәм курс эшләренә җитәкчелек иткән. Аның сигез аспиранты кандидатлык диссертацияләре яклаган. Ул зур фәнни-укыту, оештыру, мөхәррирлек, җәмәгать эшләре алып бара, шул ук вакытта бик тыйнак кеше булып кала. Аның фәнни хезмәтләре дөнья тюркологиясен шактый баета, берничә мәкаләсе Төркия, Венгрия, Германия һәм башка илләрнең фәнни басмаларында басылып чыга. Ватаныбыз Д.М. Насиловның фәнни казанышларын югары бәяли. Күпьеллык намуслы хезмәте өчен Дмитрий Михайлович «Хезмәт ветераны», «Мәскәүнең 850 еллыгы истәлегенә» медальләре, Төркия Республикасының «Лиякат» Дәүләт ордены белән бүләкләнә.

### Әдәбият

1. Диляра Гарифовна Тумашева. Серия «Биобиблиографические указатели ученых Академии наук Татарстана» / гл. ред. серии М.Х. Хасанов; сост. Ф.М. Хисамова. Казань: Фэн, 2003. 56 с.

2. *Насилов Д.М.* Программный труд академика Д.Г. Тумашевой // Диалектология, история и грамматическая структура тюркских языков. Сб. материалов междунар. тюркологической конф. 21–24 октября 2011 г. Казань, 2011. С. 9–12.

3. Реферативный журнал «Языкознание». М.: Наука, 2014. № 4.

4. *Тумашева Д.Г.* Татарский глагол. Опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий / Учеб. пособие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1986. 189 с.

5. Тумашевские чтения: актуальные проблемы развития языка, фольклора, литературы, искусства сибирских татар: материалы II Всерос. науч.-практ. конф. (Тюмень, 17 окт. 2008). Тюмень, 2008. 258 с.

6. *Шеймович А.В.* К 85-летию Галины Федоровны Благовой: научные итоги десятилетия. (Автор по нашей просьбе предоставил нам электронную версию своей статьи).

7. *Шюкрю Халык Акалын.* Дмитрий Михайлович Насилов награжден орденом Турецкой Республики «Лиякат» // Российская тюркология. Москва–Казань, 2014. № 1 (10). 116 с.

### Д.М. Насиловның төп фәнни хезмәтләре исемлеге

Монографияләр, коллектив монографияләр, уку әсбаплары

Структура времён индикатива в древнеуйгурском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1963.

Древнетюркский словарь: словарные статьи, редактор / коллектив авт. и ред. Л., 1969.

Проблемы тюркской аспектологии: Акциональность. Л.: Наука ЛО, 1989. 208 с.

Проблемы тюркской аспектологии: Акциональность: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. М., 1989. 32 с.

Expression of situational plurality in Turkic languages // Typology of Iterative Constructions / соавт.: Х.Ф. Исхакова, В.И. Рассадин. München, 1997.

Imperative sentences in Turkic languages // Typology of imperative sentences. / соавт.: И.А. Невская, Х.Ф. Исхакова, Ш. Сафаров. München: Lincom Press, 2001. P. 181–220. [на англ. яз.]

Концепция модели этнической школы для коренных малочисленных народов Севера РФ / коллектив авт. М., 2001.

Карлукско-уйгурская группа: Фонетика. Глагол // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Региональные реконструкции. М., 2002. С. 339–418.

Репрессированная тюркология / соавт.: Ф.Д. Ашнин, В. М. Алпатов. М., 2002.

Национальная школа: направления совершенствования структуры и содержания образования // Федеральная программа развития образования / коллектив авт.-сост. М., 2003.

Словарные статьи: *Л, М, Н, П* // Этимологический словарь тюркских языков / коллектив авт. М., 2003.

Уступительные конструкции в тюркских языках // Типология уступительных конструкций / соавт.: И.А. Невская, Х.Ф. Исхакова. СПб.: Наука, 2004. С. 425–452.

Программа лингвистического курса «Древнетюркские языки» // Программы курса турецкого языка и теоретических курсов / сост. Ю.В. Щека. М.: ИСАА МГУ, 2005. С. 51−54.

Программа спецкурса «Основы тюркской семантики» // Программы курса турецкого языка и теоретических курсов / сост. Ю.В. Щека. М.: ИСАА МГУ, 2005. С. 55−63.

***Алишина Хәнисә Чайдат кызы,***
*филология фәннәре докторы,*
*Төмән дәүләт университеты профессоры*

***Алишина Ханиса Чайдатовна,***
*доктор филологических наук,*
*профессор Тюменского государственного университета*
*kaf_tatarlit@utmn.ru*